**Татарстан Республикасы**
**Кукмара муниципаль районы**
**Янил авыл җирлеге башкарма комитеты**

**КАРАР**

**«31» гыйнвар 2022 ел** **№1**

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы карары, «Татарстан Республикасында «Җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы авыл җирлегенең Янил авыл җирлеге башкарма комитеты **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Янил авыл җирлегендә 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 6964,68 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл башкарма комитетында җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2021 елның 29 гыйнварындагы 1 номерлы карарын 2022 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, махсус мәгълүмат стендларында, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җитәкче И. Х. Корбанов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА ЯНИЛ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ЯНИЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТР КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ РТ
ОГРН 1061675010979
ИНН 1623008472

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 31 гыйнварындагы 1 номерлы карарына 1 нче кушымта

2022 елның 01 февраленнән
Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегендә җирләү буенча исемлектәге гарантияләнгән хезмәтләрнең
бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2974,19 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (мәетне) зиратка илтү | 957,14 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3033,35 |
| Барлыгы | 6964,68 |

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 31 гыйнварындагы 1 номерлы карарына 2 нче кушымта

2022 елның 01 февраленнән
Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегендә җирләү буенча исемлектәге гарантияләнгән хезмәтләрнең бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Кәфенләү (киендерү) | 125,22 |
| 3. Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2848,98 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (мәетен) зиратка илтү | 957,13 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3033,35 |
| Барлыгы | 6964,68 |